ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**17.03.2025**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 687**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 14 апрелендәге 1126 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 14 апрелендәге 1126 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.5.1 пунктындагы 1 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:
«1) Россия Федерациясе законнары нигезендә яисә идентификация һәм аутентификация юлы белән Россия Федерациясе гражданы паспорты яисә шәхесне таныклый торган башка документ».

1.2 2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы экспертлар тарафыннан вәкаләт бирелгән оешмалар күрсәтә торган хезмәтләр исемлеге.

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми».

1.3. 2 нче бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 2.17 пункт белән тулыландырырга:
«2.17. Муниципаль хезмәтне алдан ук (проактив) режимда күрсәтү очраклары һәм тәртибе.

Алдан ук (проактив ) режимда муниципаль хезмәт күрсәтелми».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми (htpp:/pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат

(http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин